ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 02 2021 ел № 54

«Балтач муниципаль районы шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирлегендә эшләүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2017 елның 22 апрелендәге 82 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарына (2017 елның 7 сентябрендәге 148 номерлы, 2020 елның 29 сентябрендәге 192 номерлы үзгәрешләр белән) өстәмәләр кертү хакында

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы Беркетмәсенең 24, 25 пунктларын үтәү йөзеннән, шулай ук «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2020 елда эш йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы РН-12-26 номерлы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы коллегиясе йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Премьер-министрының Беренче урынбасары Р.К. Нигъмәтуллин йөкләмәләре исемлеген үтәү йөзеннән, Балтач муниципаль районы Башлыгы карар бирә:

1. «Балтач муниципаль районы шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирлегендә эшләүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 2017 елның 22 апрелендәге 82 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карарының (2017 елның 7 сентябрендәге 148 номерлы, 2020 елның 29 сентябрендәге 192 номерлы үзгәрешләр белән) 1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«дәүләт мәгариф учреждениеләрендә эшләүче һәм авыл торак пунктларында, шәһәр тибындагы поселокларда яшәүче мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына.».

1.2. 1.1. пунктчаны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1.1. Субсидияләрне алу өчен Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмаска тиеш.».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы
Башлыгы Р.Р.Нотфуллин